**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«15» 05 2020 ел № 1823

Хезмәткә һәм оборонага әзер (ГТО) комплексын гамәлгә ашыру турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль законның 31.2 статьясы 3 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын гамәлгә ашыру турында» 2014 елның 4 сентябрендәге 1763-р номерлы карары нигезендә, «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау нормативларын үтәү буенча халыкка сынау үткәрү һәм оештыру максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үткәрү үзәге турында нигезләмәне расларга.
2. Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәүне бәяләү хокукы бирергә.
3. Тукай муниципаль районының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үткәрү үзәге җитәкчесе итеп Низамиева Азалия Ринат кызын билгеләргә.
4. Тукай муниципаль районының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үткәрү үзәге баш судьясы итеп Иванов Руслан Валентиновичны билгеләргә.
5. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 18 июнендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спорт өлкәсендә сынау (тест) төрләрен, нормативларны, белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә таләпләрне үтәү буенча тест үткәрү үзәген төзү турында» 2197 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 15.05 1823 номерлы карарына кушымта

Тукай муниципаль районының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үткәрү үзәге турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Тукай муниципаль районының «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының сынау (тест) нормативларын үтәү буенча тест үткәрү үзәге турында нигезләмә (алга таба – нигезләмә, тест үткәрү үзәге) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 11 июнендәге 540 номерлы карары белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы турында нигезләмәнең 26 пункты нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының (алга таба – ГТО комплексы) нормативларын үтәү, белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләү нәтиҗәләре нигезендә халыкның гомуми физик әзерлеге дәрәҗәсенә тест үткәрүне гамәлгә ашыра торган тест үткәрү үзәген оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели.

## II. Тест үткәрү үзәгенең максатлары һәм бурычлары

2.1. Тест үткәрү үзәге эшчәнлегенең төп максаты булып, Россия Федерациясе Спорт министрлыгының 2014 елның 8 июлендәге 575 номерлы боерыгы белән расланган ГТО комплексы нормативларын үтәгәндә, гражданнар тарафыннан халыкның физик әзерлек дәрәҗәсенә дәүләт таләпләрен (алга таба – дәүләт таләпләре) үтәүне бәяләү тора.

2.2. Тест үткәрү үзәгенең бурычлары булып тора:

2.2.1. Физик культура һәм спорт өлкәсендә сынаулар (тестлар) төрләрен, нормативларны, белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә карата таләпләрне үтәү өчен әзерләктә халыкка консультацион һәм методик ярдәм күрсәтү буенча шартлар тудыру;

2.2.2. Физик культура һәм спорт өлкәсендә сынаулар (тестлар) төрләрен, нормативларны, белем һәм осталык дәрәҗәсен бәяләүгә карата таләпләрне үтәү буенча халыкка тест үткәрүне оештыру һәм уздыру.

2.3. Тест үткәрү үзәге эшчәнлегенең төп төрләре булып тора:

2.3.1. Халыкта физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә, физик камилләшүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен алып баруга, ГТО комплексы

нормативларын һәм сынауларны (тестларны) үтәү буенча чараларда катнашуны популярлаштыруга юнәлтелгән пропаганда һәм мәгълүмати эш алып бару;

2.3.2. Дәүләт таләпләрен үтәүгә әзерлектә халыкка, спорт, иҗтимагый һәм башка оешмаларга шартлар тудыру, консультацион һәм методик ярдәм күрсәтү;

2.3.3. Россия Спорт министрлыгының 2014 елның 29 августындагы 739 номерлы боерыгы белән расланган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы кысаларында Халыкка тест үткәрүне оештыру һәм уздыру тәртибе нигезендә (алга таба – Тест үткәрүне оештыру һәм уздыру тәртибе) физик әзерлек дәрәҗәсенә карата дәүләт таләпләрен үтәү һәм гражданнарның белем һәм күнекмәләрен бәяләү буенча халыкка тест үткәрүне гамәлгә ашыру;

2.3.4. Тест уздыру урыннарында катнашучыларның күрсәтелгән тест үтү нәтиҗәләре исәбен алып бару, ГТО комплексы нормативларын үтәү беркетмәләрен формалаштыру, Тестларны оештыру һәм үткәрү тәртибе таләпләре нигезендә гомумиләштерү өчен әлеге беркетмәләрне тапшыруны тәэмин итү;

2.3.5. Тестларда катнашучыларның мәгълүматларын, тест үтү нәтиҗәләрен һәм җыелма беркетмә мәгълүматларын ГТО комплексының автоматлаштырылган мәгълүмат системасына кертү;

2.3.6. Регионара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чаралары һәм спорт чаралары бердәм календарь планына, муниципаль берәмлекләрнең физкультура чаралары һәм спорт чаралары календарь планнарына кертелгән ГТО комплексы чараларын оештыруда катнашу;

2.3.7. ГТО комплексын гамәлгә кертү, ГТО комплексы чараларын уздыру мәсьәләләрендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү;

2.3.8. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булганда, физик культура һәм спорт өлкәсендә белгечләрнең ГТО комплексы буенча квалификациясен күтәрүне оештыруда катнашу;

2.3.9. Халыкка тест үткәрү буенча судьялар булуны тәэмин итү

2.4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында тест үткәрүне оештыру өчен тест үткәрү үзәгенең күчмә комиссиясе оештырыла.

2.5. Тест спорт объектлары өчен, шул исәптән эксплуатацияләү куркынычсызлыгы буенча, билгеләнгән таләпләргә туры килә торган урыннарда гына оештырыла.

## III. Якларның үзара хезмәттәшлеге

3.1. Тест үткәрү үзәге хокуклы:

3.1.1. Тест үткәрүне оештыру һәм уздыру тәртибе һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә ГТО комплексы сынаулары (тестлары) төрләрен үтәүгә катнашучыларны кертергә һәм кертмәскә;

3.1.2. Тест үткәрүдә катнашучылардан, җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан үз эшчәнлеге өчен кирәкле мәгълүматны соратырга һәм алырга;

3.1.3. ГТО комплексының структурасын һәм дәүләт таләпләре эчтәлеген камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

3.1.4. Гражданнарга тест үткәрү процессын оештыру өчен волонтерларны җәлеп итәргә.

3.2. Тест үткәрү үзәге бурычлы:

3.2.1. Спорт һәм физкультура чараларын үткәрүне регламентлаштыручы Тестларны оештыру һәм үткәрү тәртибе, башка норматив-хокукый актлар таләпләрен үтәргә;

3.2.2. ГТО комплексы кысаларында тест һәм башка чаралар үткәргәндә медицина ярдәме күрсәтүне оештыру өчен шартлар тәэмин итәргә.

## IV. Матди-техник тәэмин ителеш

4.1. Тест үткәрү үзәкләрен матди-техник яктан тәэмин итү гамәлгә куючы акчалары, үз средстволары һәм Россия Федерациясе законнары кысаларында җәлеп ителгән башка средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

4.2. Үзәк тест үткәрүдә катнашучыларны матди-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра, тест үтү өчен кирәкле спорт җиһазлары һәм инвентарь белән тәэмин итә.